
*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Мөнәҗәтләр турында исеңә төшер. Аларның үзенчәлекләрен барлап яз, мисаллар китер. (7 балл)**

**2. Рәсемгә игътибар ит. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз, әсәр геройларын ата. (6 балл)**



**3. Әсәрләрнең авторын, жанрын яз. (6 балл)**

а) «Бездә яздыр» ______________________ ____________________

ә) «Моңлы бер җыр» ______________________ ____________________


б) «Буранда» ______________________ ____________________

4. **Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгелә. (6 балл)**

Авыруыма табиб кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын:
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын.

Язар өчен илһам эзлә, диләр,
Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.
Никтер минем шигъри хисләремә
Арышларның исе тәмлерәк!

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп яз. (10 балл)**



1) ___________________________
2) ___________________________
3) ___________________________

**6. Сыерчык диңгез артына китсә дә үз туган оясына кайта, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**